**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 июль № 508

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлекнең 4.1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы белән килештерү буенча геральдик билгене – Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәтенең эмблемасын, флагын гамәлгә куярга.»;

5 бүлекнең 5.1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Баш ветеринария идарәсе башлыгының ике урынбасары була, һәм алар Баш ветеринария идарәсе башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфаларына билгеләнә һәм вазыйфаларыннан азат ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\508.docx